# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында
Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, №12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2010, 31 март, 2 апрель, 29 июнь, 7 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7.1 статьяда “2.7” санын “2.5” санына алмаштырырга;

2) 7.4 статьяда “әлеге Кодексның” сүзләреннән соң “2.6, 2.7,” саннарын өстәргә;

3) 8.1 статьяда:

бишенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы һәм унынчы өлешләрне өстәргә:

“Әлеге статьяның беренче, икенче, дүртенче, алтынчы өлешләрендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 2.6, 2.7, 3.2 – 3.7, 4.2, 4.4, 5.1, 5.2, 5.3 – 5.6 статьяларында (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажир йөртүләргә карата), шулай ук 6.1 – 6.3 статьяларында (җирле бюджет акчалары өлешендә) каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне җирле үзидарә органнарының әлеге өлештә күрсәтелгән статьяларда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи затлары төзергә хокуклы.

Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары әлеге статьяның тугызынчы өлешендә каралган очракларда җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы тарафыннан тапшырылган контроль (күзәтчелек) вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, шулай ук муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.";

тугызынчы өлешне унберенче өлеш дип санарга һәм аңа ", шулай ук җирле үзидарә органнарына тиешле дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракта алар тарафыннан." сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 61-ТРЗ